**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**16 июнь 2023 ел** **№ 70**

**2018 нче елның 4 нче маендагы Красносельский авыл җирлеге Советының 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Красносельский авыл җирлеге Уставына таянып, законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2018 елның 4 маендагы 85 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» (2018 елның 24 сентябрендәге 96 нче номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 4 нче номерлы, 2022 елның 26 октябрендәге 55 нче номерлы, 2022 елның 25 ноябрендәге 60 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1 нче пунктта 15 нче абзацны чыгарырга;
- «Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләү өчен айлык процент өстәмәсе күләме һәм муниципаль хезмәткәрнең вазифа хезмәт хакы күләме»12 нче кушымтаны чыгарырга;
- «Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә еллар буе хезмәт иткән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында Нигезләмә» 13 нче кушымтаны 12 нче кушымта дип санарга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау тимер юл станция поселогы, Совет урамы, 13 йорт адресы буенча,Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында урнашкан мәгълүмат стендында, Татарстан

Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Красносельский авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Никитенко Р.Р. йөкләргә.

Красносельский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко